| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**14 ноябрь 2024ел.** Түбән Урысбага **№ 182**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен бирергә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлегенең башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру Түбән Ураысбага авыл җирлеге бюджетыннан ел саен Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. 2024 елның 14 мартындагы 158 номерлы карар. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләрен бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы)

адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Урысбага авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Х.Х.Сибгатуллин.